| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ЗАРЕЧЕНСК<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Зареченск авылы

10.09.2021нче ел № 18

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы
Яңа Зареченск авыл җирлеге
Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү
һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»
04.08.2021 ел №14 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.08.2021 ел №14 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 һәм 10 абзацлары. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт адреслы реестрын алып бару һәм федераль мәгълүмати адреслы системаны эксплуатацияләүгә бәйле регламентта кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат системасы турында” 28.12.2013 ел № 443-ФЗ Федераль закон Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару Кагыйдәләрен

раслау турында" 19.11.2014 ел, № 1221 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән төгәл итеп кулланыла.»;

1.2. 1.5 пунктының 11 – 17 абзацлары 3-9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет»сүзләренә алмаштырырга.;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында. «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4 пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «Муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Яңа Зареченск авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Шарифуллина